КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 март г.Казань № 226

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие бирү чыгымнарын финанслау тәртибен раслау турында» 2019 ел, 20 декабрь, 1181 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие бирү чыгымнарын финанслау тәртибен раслау турында» 2019 ел, 20 декабрь, 1181 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына ай саен пособие бирү чыгымнарын финанслау тәртибен раслау»;

преамбулада «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган» сүзләреннән соң «, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә булса да инвалид бала булган» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган» сүзләреннән соң «, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә булса да инвалид бала булган» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган» сүзләреннән соң «, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә булса да инвалид бала булган» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие бирү чыгымнарын финанслау тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына ай саен пособие бирү чыгымнарын финанслау тәртибе»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына ай саен пособие бирү турында» 2019 ел, 7 сентябрь, 803 нче карары белән расланган 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына ай саен пособие (алга таба шул ук эзлеклелектә – пособие, пособие алучылар) бирү чыгымнарын финанслау механизмын билгели.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин